**ГЛАВА НИКОЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**422627 , с.Никольское ,**
**ул. Центральная , д 35**
**тел: 4-31-44**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НИКОЛЬСКИЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
**422627 Никольский авылы,**
**Үзәкурамы , 35 нчыйорт,**
**Тел : 4-31-44**

---

**2022елның 17 августы** **10 номер**

# КАРАР

**Кадастр номеры 16: 24: 050802:404 булган җир кишәрлеген планлаштыру һәм межалау проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына таянып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Никольский авыл җирлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы»муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә таянып, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренең уңай яшәү шартларына хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында, карар итәм:

1. Кадастр номеры 16: 24: 050802:404 булган җир кишәрлеген планлаштыру һәм межалау проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Ачык тыңлаулар үткәрү чорын - кызыксынган затларга аларны үткәрү турында хәбәр итү вакытыннан гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә бастырылган көнгә кадәр дип билгеләргә. Ачык тыңлауларны үткәрү вакыты бер айдан да ким өч айдан артык булмаска тиеш;

3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Никольский авыл җирлеге Башкарма комитетына:

3.1. Гавами тыңлаулар башлану турында хәбәрнамә әзерләргә.

3.2. Әлеге карар үз көченә кергән көннән 14 эш көне эчендә әлеге карарның 3.1 пунктында күрсәтелгән хәбәрнамәне авыл җирлеге уставында билгеләнгән тәртип нигезендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә);

3.3. Әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән чорда ачык тыңлаулар үткәрергә.

4. Әлеге карарны авыл җирлеге уставында билгеләнгән тәртип нигезендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Никольский авыл җирлеге башлыгы** **Э.Х. Алеев**